ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.02.2024 ел Баулы шәһәре №23

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 сентябрендәге 169 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бушлай милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ :

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 сентябрендәге 169 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бушлай милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 15 февралендәге 37 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлектә «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты»:

2.8.2.1.пунктның 8 пунктчасында «төзелгән территорияләр үсеше» сүзләрен «территориянең комплекслы үсеше» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров